Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитеты
карары

26 май 2020 ел № 682

Транспорт чаралары хәрәкәтен
вакытлыча ябу турында

«Әлмәт-Водоканал» АҖнең 2020 елның 25 маендагы 8843 номерлы ремонтка кагылышлы эшләр турындагы мөрәҗәгатенә бәйле рәвештә

БАШКАРМА КОМИТЕТ КАРАР БИРӘ:

1. 2020 елның 27 маеннан 29 маена кадәр Ленин урамыннан Белоглазов урамына кадәр участокта Муса Җәлил урамында транспорт чаралары хәрәкәтен вакытлыча ябырга.

2. «Әлмәт-Водоканал» акционерлык җәмгыятенә әлеге участокта транспорт чаралары хәрәкәтенең «Торак сәясәте һәм торак-коммуналь хуҗалыгы департаменты» муниципаль автоном учреждениесе (Сөләйманов З.А.) белән ябылуын килештерергә, тиешле юл билгеләре урнаштырырга һәм су белән тәэмин итү блоклары белән эшләү участогын киртәләргә.

3. Эш участогын ябу чорында Муса Җәлил урамын әйләнеп үтүне Гагарин, Мәрҗани урамнары буйлап башкарырга.

4. Район Башкарма комитетының Хокук идарәсенә (Ханнанова Ә.Б.) әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) урнаштырырга .

5. Массакүләм мәгълүмат чаралары белән эшләү бүлегенә (Зарипова Л.Н.) халыкка транспорт чаралары хәрәкәтен вакытлыча ябу турында хәбәр итәргә.

6. Әлеге карар 2020 елның 27 маеннан үз көченә керә.

7. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны район Башкарма комитеты җитәкчесенең төзелеш буенча урынбасары Д. В. Косаревка йөкләргә.

Район
Башкарма комитеты җитәкчесе М.Н. Гирфанов